ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАРЫ

№ 9 02.11. 2022 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино
авыл җирлегенең Медянка торак пунктында
гражданнарның үзара салымнарын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Медянка торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Тимошкино авыл җирлеге Медянка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә , моннан тыш, 1 төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Украинадагы махсус операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаиләләреннән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала; Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

**1. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);**
**2. Ритуал хезмәтләрен оештыру һәм күмү урыннарын тәртиптә тоту**
**- Иске Тимошкино зиратында агач һәм үсентеләр кисү килешүе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү**
**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Медянка авылы Луговая урамындагы сулыкны чистарту (эшләр башкару, килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Аксубай районының Медянка авылы, Луговая урамы 8а йорт адресы буенча урнашкан мәктәп янында гражданнар җыенын үткәрергә.

**4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, стендларда һәм белдерү такталарында элену юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк.**

**5.Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.**

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы : П.А.Мулеева